**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6016**
**01.11.2022**

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. 2018 елның 25 апрелендә «Челнинские известия» газетасының 29 нчы санында бастырып чыгарылган Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 10 апрелендәге 1950 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2022 елның 1 ноябрендәге
6016 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Транспорт чараларын саклау хезмәтләре | | | |
| 1. | Җиңел автомобиль | ай/тәүлек | 1000,00/100,00 |
| 2. | Микроавтобус | ай/тәүлек | 1200,00/100,00 |
| 3. | Трактор | ай/тәүлек | 1300,00/150,00 |
| 4. | Йөк автомобиле | ай/тәүлек | 1500,00/150,00 |
| 5. | Тагылма | ай/тәүлек | 600,00/50,00 |
| 6. | Самокат | ай/тәүлек | 500,00/50,00 |
| II. Ял һәм спорт өчен товарларны прокатка бирү буенча хезмәтләр | | | |
| 1. | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 90,00 |
| 2. | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 120,00 |
| 3. | Тимераяклар үткенләү | 1 хезмәт | 100,00 |
| 4. | Әйберләрне саклау | 1 сәгать | 30,00 |
| III. Спорт әзерлеге буенча оештыру хезмәтләре. Хайваннарны прокатка бирү | | | |
| 1. | Спорт атына атланып йөрү буенча тренер белән индивидуаль дәресләр | 1 сәгать | 1000,00 |
| 2. | «Тулпар» АСМ – «Яр буе» паркы маршруты буенча тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | 1 сәгать<br>1 сәгать | 500,00<br>300,00 |
| 3. | «Тулпар» АСМ территориясендә тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | 1 сәгать<br>1 сәгать | 300,00<br>200,00 |
| 4. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига<br>- ишәккә атланып йөрү | 1 урын<br>1 маршрут | 300,00<br>200,00<br>150,00 |
| 5. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә атлы чаналарга, фаэтонга, каретага утырып йөрү | 1 урын<br>1 маршрут | 200,00 |
| 6. | Атта фотосессия | 1 сәгать | 3000,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева